КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 26 май г.Казань № 357

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 185 нче; 2022 ел, 9 июль, 659 нчы; 2022 ел, 7 декабрь, 1297 нче; 2023 ел, 11 апрель, 447 нче; 2023 ел, 12 октябрь, 1301 нче; 2024 ел, 2 март, 116 нчы; 2024 ел, 20 ноябрь, 1024 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы

территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктта татар текстында «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

3.5 пунктның «б» пунктчасындагы егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«иҗтимагый оешма һәм чит оешмалар арасында төзелгән шартнамәләр (килешүләр), социаль әһәмиятле чаралар уздыру өчен җәлеп ителгән белгечләр белән граждан-хокукый шартнамәләр, әлеге шартнамәләрнең (килешүләрнең) үтәлеше турында иҗтимагый оешманың мөһере (булган очракта) белән беркетелгән беренчел документация;»;

3.16 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.18 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге беркетмәнең яңа версиясен булдыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Вәкаләтле орган түбәндәгеләргә бурычлы:

а) сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү төгәлләнгән дата җиткәнгә кадәр, түбәндәге шартларны үтәп гамәлгә ашырыла:

иҗтимагый оешмалар тарафыннан заявкаларны бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә субсидияләр алучыларны сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә иҗтимагый оешмаларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы карала торган нигезләмә кертелә;

заявка биргән иҗтимагый оешмаларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә;

б) әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары вәкаләтле органга киметелгән (кире алынган) очракта, сайлап алуны уздыруны гамәлдән чыгарырга.

Бердәм порталда вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны уздырмау турында белдерү иҗтимагый оешмалар тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.»;

5.1 пунктның икенче абзацында «Электрон бюджет» системасында» сүзлә-

реннән соң «(техник мөмкинлекләр булганда)» сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктның өченче абзацында «вәкаләтле орган тарафыннан» сүзләреннән соң «әлеге Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документлар каралу һәм тикшерелү нәтиҗәләре буенча» сүзләрен өстәргә;

5.6 пунктта татар текстында «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

7.2 пунктта «нәтиҗәләргә ирешү мониторингын уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча» сүзләрен «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибе нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин